**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**07.11.2017** **№ 01-02/137**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 10 декабрендәге 01-02/798 номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Министрлык, дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, боерам:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 10 декабрендәге 01-02/798 номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Министрлык» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Министрлык, дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршындагы Иҗтимагый советны булдыру тәртибе нигезендә» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Министрлык, дәүләт комитеты, Татарстан

Республикасы ведомствосы каршында Иҗтимагый совет булдыру тәртибе нигезендә формалаштырыла.

Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә Министрлык тарафыннан составында ихтыяри катнашу нигезендәге 10 кешедән булдырыла.

3.2. Министрлык Иҗтимагый совет составы расланганнан соңгы 30 көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын уздыруны оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның рәисе һәм рәис урынбасары сайлана. Карар ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый советның гомуми әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.3. Иҗтимагый совет рәисен яки рәис урынбасарын вазыйфаларыннан бушату турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы юстиция министры мөрәҗәгате нигезендә, шулай ук Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының шәхси гаризасы нигезендә яки Иҗтимагый совет әгъзаларының Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан биштән бер өлешеннән дә кимрәк булмаган сандагы төркеме тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала. Карар Иҗтимагый советның гомуми әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.4. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый советның җаваплы секретарен Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан билгели.

3.5. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре вакыты Иҗтимагый советның яңа формалаштырылган составының беренче утырышы уздырылган көннән алып өч ел.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме нигезендә түбәндәге очракларда Министрлык боерыгы белән туктатыла:

ул Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләнгән очракта;

аңа административ кулга алу төрендәге административ җәза бирелгәндә;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайлаулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яки вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәгәндә, шулай ук аның Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатив төркем составына керүе очрагында.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

вәкаләтләре вакыты чыкканда;

аның тарафыннан Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирелгәндә;

сәламәтлеге буенча Иҗтимагый совет эшендә катнашуга сәләтсез булганда;

судның аңа карата чыгарылган гаепләү хөкеме законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә эшкә сәләтсез дип яки хәбәрсез кая да булса киткән дип танылганда;

этик нормаларны тупас бозганда – утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

игътибарга лаеклы сәбәпсез системалы рәвештә (рәттән өч тапкырдан күбрәк) Иҗтимагый совет утырышы эшендә катнашмаганда;

Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары йөкләмәләрен игътибарга лаеклы сәбәпсез системалы төстә (рәттән ике тапкырдан күбрәк) үтәмәгәндә;

аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына, муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә;

чит ил гражданлыгын алганда;

Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вазыйфаларын туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы нигезендә яки Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының тәкъдиме белән, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган хәлләр ачыкланган очракта, Министрлык боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктының дүртенче, бишенче, унынчы-уникенче абзацларында каралган хәлләр килеп чыгуы турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.»;

Нигезләмәнең 5.4 пунктының өченче абзацына түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәргә:

«Тавышлар саны тигез булганда Иҗтимагый совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.»;

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге 5.12.1 пункт өстәргә:

«5.12.1. Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары катнашуны тәэмин итә.»;

5.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Министрлык гамәлгә ашыра.».

Министр Р.И. Заһидуллин